Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советы
КАРАРЫ

17 декабрь 2025 ел № 8

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы турында» 2013 елның 25 ноябрендәге 156 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Салым кодексының 387 статьясындагы икенче өлешенең 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясына таянып,

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы турында» 2013 елның 25 ноябрендәге 156 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2013 елның 24 декабрендәге 169 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге 200 номерлы, 2014 елның 19 ноябрендәге 211 номерлы, 2015 елның 5 маендагы 239 номерлы, 2020 елның 14 маендагы 184 номерлы, 2020 елның 25 ноябрендәге 8 номерлы, 2023 елның 26 сентябрендәге 94 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 103 номерлы, 2024 елның 16 июлендәге 118 номерлы, 2025 елның 12 маендагы 141 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5 пунктның җиденче абзацында «1 елга» сүзләрен «2026 елның 01 гыйнварына кадәр»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе, Некрасов ур, 18А йорты, 30А йорты, Завод ур., 2А йорты, Достоевский ур., 10 йорт, Х.Атласи ур., 1А йорты, Совет ур., 84 йорт һәм Тихоновка авылы, Терешкова ур., 34А йорты торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә башлыгына йөкләргә.

Түбән Мактама шәһәр тибындагы
бистә башлыгы В.Н. Сенин